

# Югары бүләгегез белән, Фәрид Рәшидович!

2023 елның 14 апрелендә авылдашыбыз, Татарстанның атказанган төзүчесе, Яр Чаллы шәһәре Сәүдә-сәнәгать палатасы генераль директоры Фәрид Рәшид улы Бәшәровка “Татмедиа” акционерлык җәмгыяте, “Мәйдан” журналы редакциясе, Татарстан Республикасы Язучылар берлегенең уртак карары нигезендә Илдар Юзеев исемендәге әдәби-иҗтимагый премиясе бирелде.

Барлык авылдашлар, якташлар, сайт укучылары исеменнән Фәрид Рәшид улы Бәшәровны бу олы бүләге белән котлыйбыз, аңа алга таба саулык-сәламәтлек, бәхетле тормыш һәм яңа уңышлар телибез!



«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте филиалы –
«Мәйдан» журналы редакциясе
Татарстан Республикасы Язучылар берлеге

# ИЛДАР ЮЗЕЕВ
## *исемендәге әдәби-иҗтимагый премия*



«Мәйдан» әдәби-нәфис, иҗтимагый журналының
2022 ел, № 8 санында басылып чыккан шигырьләр циклы
һәм актив әдәби-иҗтимагый эшчәнлеге өчен
шагыйрь, язучы, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге әгъзасы
ӘЛФИЯ МИРЗАНУР кызы СИТДЫЙКОВАга бирелә.



«Мәйдан» әдәби-нәфис, иҗтимагый журналының
2022 ел, № 10 санында басылып чыккан чәчмә әсәрләре
һәм актив әдәби-иҗтимагый эшчәнлеге өчен
Башкортстанда яшәп иҗат итүче татар язучысы
ХИСАМЕТДИН ШӘРӘФЕТДИН улы ИСМӘГЫЙЛЕВка бирелә.



«Мәйдан» әдәби-нәфис, иҗтимагый журналын яшәтүгә,
абруен күтәрүгә һәм милли рухиятебезне үстерүгә керткән
күпьеллык нәтиҗәле эшчәнлеге өчен
шагыйрь, язучы, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге әгъзасы
РӘШИТ ГАФФАР улы БӘШӘРОВка бирелә.



«Мәйдан» әдәби-нәфис, иҗтимагый журналына
озак еллар дәвамында ярдәм күрсәтүе өчен
Яр Чаллы шәһәре Сәүдә-сәнәгать палатасы генераль директоры
ФӘРИД РӘШИД улы БӘШӘРОВка бирелә.

*ТР Язучылар берлеге рәисе* — *Р. Р. Зәйдуллин*
*«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы җитәкчесе –*
*«Шәһри Чаллы» редакциясе баш мөхәррире* — *Р. М. Юсупова*
*«Мәйдан» журналы баш мөхәррире* — *Л. Р. Фәттахова*

14 апрель 2023 ел